**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы вәкаләтле вәкиле функцияләрен йөкләү турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Татарстан Республикасы Рәисе мәнфәгатьләрендә эш алып баруны тәэмин итү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе Нагуманов Тимур Дмитрий улына Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы вәкаләтле вәкиле функцияләрен башкаруны йөкләргә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Татарстан Республикасы Президентының тулы вәкаләтле вәкиле функцияләрен тормышка ашыру мәсьәләләре» 2013 елның 13 сентябрендәге ПУ-895 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 15 ноябрь
№ 882